# Күңел сандыгында ниләр бар?




Хәлимә ГЫЙМАЗОВА
Вакытсыз сулган чәчәкләр


Хәлимә ГЫЙМАЗОВА
Күңел сандыгынданиләр бар?





Сез кайдан дип сорасагыз – без Калмаштан,
Моңнар алдык чишмәләрдән, сандугачтан.
Татар моңы ишетелә һәр тарафтан,
Моңлы илем туган җирем “Татарстан”.




21/08/2009







Мөнәҗәтләр кичәсендә, 2012 ел






Изге Биләргә сәяхәт, 2008 ел

Иҗат концерты, 2005 ел

# ӘБИЛӘР ЧУАГЫ

Кояшлы җәйләрне хәтерләттең,
Исәнме, әбиләр чуагы!
Уйланып утырамын капка төбендә,
Уйларым таралды, зиһенем чуалды...
Уфтанмыйк әле бу гомерләр үтә, дип,
Яшәүдән дә рәхәт нәрсә бар соң тагын?
Кадерен белеп кал, чык капка төбенә,
Урамда – әбиләр чуагы.
Яфраклар коела, күңелне моң сара,
Күзләрем яшьләнде керфегем чыланды.
Боекты күңелем, бик матур көн бүген,
Җиһанда – әбиләр чуагы.



# ИКЕ КЫЗЫМ



Су буенда йөзә ике аккош,
Әллә инде минем казларым.
Пар алмагач – пар сандугач,
Ике гөлем – ике кызым,
Әллә инде минем кызларым?







# РАББЕМ, ҮЗЕҢ САКЛА

Шәмдәлемдә соңгы шәмем яна,
Ни эшләрмен караңгыда калсам, берүзем...

Караңгыдан, ялгызлыктан куркам,
Раббем, үзең сакла, бир түзем...





Язмыш дигәннәре балдан татлы,
Миләш, баланнардан ачы икән.
Рәхмәт ачы-татлы язмышыма,
Язмышлардан узмыш юк икән.

Тормыш дигәннәре сикәлтәле,
Борма-борма урау юл икән.
Аллаһ язган язмыш дөрес икән,
Язмышлардан узмыш юк икән.